КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 май г.Казань № 443

«Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 24 маендагы ПУ-295 номерлы Указы нигезендә һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру, үстерү һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы учреждениеләре өчен бюджет исәбе һәм хисаплылык» мәгълүмат системасын «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы итеп билгеләргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) турындагы нигезләмәне расларга.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгын – аңа Системаны булдыру, үстерү һәм аңа техник ярдәм күрсәтү, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны техник саклау буенча чаралар үткәрүне тәэмин итү вәкаләтләрен биреп, Системаның дәүләт заказчысы итеп;

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгын – Системаның мәгълүматлар базасын тулыландыру актуальлеген һәм корректлылыгын мониторинглау һәм Система эшләвенә карата таләпләр формалаштыру функцияләре белән Системаның функциональ операторы итеп.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин